**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

№ 15/2

«10» декабрь 2021 ел

**2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар планы чорына** Бәтке **авыл җирлеге бюджеты турында**

1 статья

1. 2022елга Бәтке авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Бәтке авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләмен 11981,60 мең сум итеп;

2) Бәтке авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 11981,60 мең сум итеп;

3) Бәтке авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 0 сум итеп.

2. 2023 елга һәм 2024 елга Бәтке авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) 2023 елга Бәтке авыл җирлеге бюджет керемнәренең гомуми күләмен 11957,16 мең сум, 2024 елга – 12100,83 мең сум итеп;

2) Бәтке авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен:

- 2023 елга 11957,16 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны – 291,7 мең сум;

- 2024 елга 12100,83 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 590,29 мең сум күләмендә;

3) 2023 елга Бәтке авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 0 сум һәм 2024 елга 0 сум итеп.

3. Бәтке авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын расларга:

- 2022 елга әлеге карарга 1 кушымта нигезендә;

- 2023 һәм 2024 еллар планы чорына әлеге карарга 2 кушымта нигезендә.

2 статья

1. 2023 елның 1 январена Бәтке авыл җирлеге эчке муниципаль бурычының югары чиген 0 сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 сум күләмендә расларга.

2. 2024 елның 1 январена Бәтке авыл җирлеге эчке муниципаль бурычының югары чиген 0 сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 сум күләмендә расларга.

3. 2025 елның 1 январена Бәтке авыл җирлегенең муниципаль эчке бурыч чиген 0 сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 сум күләмендә расларга.

3 статья

1. Бәтке авыл җирлеге бюджетында 2022 елга фаразланган керемнәр күләмен әлеге карарга 3 кушымта нигезендә исәпкә алырга.

2. Бәтке авыл җирлеге бюджетында 2023 һәм 2024 еллар планы чорына фаразланган керемнәр күләмен әлеге карарга 4 кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

1. Бәтке авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 5 кушымта нигезендә расларга.

2. Бәтке авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 6 кушымта нигезендә расларга.

5 статья

1. 2022 елда һәм 2023, 2024 еллар планы чорында Бәтке авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына әлеге маддәдә каралган бюджетара субсидияләрне күчерү ай саен тигез өлешләр белән башкарыла.

6 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.13 статьясы нигезендә Бәтке авыл җирлеге бюджетыннан Тукай муниципаль районы бюджетына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар күләмен расларга:

- төзекләндерү кысаларында авыл җирлекләре автомобиль юлларын карап тоту (юлларны кышкы чистарту) буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тапшыруга 2022 елга – 888,3 мең сум, 2023 елда – 888,3 мең сум, 2024 елда 888,3 мең сум күләмендә;

- территорияне төзекләндерү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тапшыруга 2022-2024 елга 365,79 мең сум күләмендә;

- җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ялны оештыру өчен шартлар тудыру буенча чараларны тәэмин итүгә төзелгән килешүләр буенча 2022 елга – 1104,6 мең сум, 2023 елга – 1104,6 мең сум, 2024 елга 1104,6 мең сум күләмендә.

2022-2024 елда бюджетара трансфертларны күчерү ай саен тигез өлешләр белән башкарыла дип билгеләргә.

7 Статья

" Бәтке авыл җирлеге бюджетында 2022 елга хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне

тормышка ашыру өчен субвенция күләмен 279,0 мең сум күләмендә, 2023елга 284,0 мең сум күләмендә, 2024 елга 290,0 мең сум күләмендә расларга.

8 Статья

Бәтке авыл җирлеге бюджетында Тукай муниципаль районы бюджетыннан 2021 елга бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен тигезләүгә 5,0 мең сум, 2022 елга 5,0 мең сум, 2023 елга 5,0 мең сум күләмендә дотацияләр күләмен расларга.

9 Статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.13 статьясы нигезендә Бәтке авыл җирлеге бюджетыннан Тукай муниципаль районы бюджетына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар күләмен расларга:

2022-2024 елда бюджетара трансфертларны күчерү ай саен тигез өлеш белән башкарыла дип билгеләргә.

10 статья

2022 елда Бәтке авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

11 статья

Товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Бәтке авыл җирлеге исеменнән төзелгән контрактлар өчен түләүгә (әлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2018 елда түләнергә тиеш) файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре калдыгы суммасыннан артмаган күләмдәге Бәтке выл җирлеге бюджеты калдыклары 2022елда, Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

12 статья

Әлеге карарны Бәтке авылы территориясендәге (Гагарин урамы, 1, административ бина) махсус стендларда урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

13 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Бәтке авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

14 статья
Әлеге карар 2022 елның 1 январеннан үз көченә керә.

ТР Тукай муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы В.А.Валиева